ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина , д. 29, г. Казань , 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон:(843)211-66-94, факс:(843)211-66-47, E-Mail:ojm@tatar.ru, сайт:http://ojm.tatarstan.ru

Приказ — Казан ш. — Боерык

18.03.2025 — № 47-од

«Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 16 маендагы 124-од номерлы Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Аучылык билетын, аучылык билеты формасын бирү һәм гамәлдән чыгару тәртибен раслау турында» 2024 елның 24 сентябрендәге 579 номерлы боерыгын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары нигезендә физик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү, Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының структур бүлекчәләренең дәүләт хезмәте күрсәтү эшчәнлеген регламентлаштыру һәм стандартлаштыру максатларында боерам:

1. «Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 16 маендагы 124-од номерлы Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты боерыгына (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 14 ноябрендәге 344-од номерлы, 2019 елның 12 декабрендәге 387-од номерлы, 2020 елның 19 августындагы 247-од номерлы, 2020 елның 16 ноябрендәге 350-од номерлы, 2021 елның 24 августындагы 247-од номерлы, 2022 елның 26 сентябрендәге 344-од номерлы, 2023 елның 02 августындагы 223-од номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Россия Табигать министрлыгының «Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын, аучылык билеты формасын бирү һәм гамәлдән чыгару тәртибен раслау турында» 2011 елның 20 гыйнварындагы 13 номерлы боерыгы» сүзләрен «Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару тәртибен, аучылык билеты формасын раслау турында» 2024 елның 24 сентябрендәге 579 номерлы боерыгы сүзләренә алмаштырырга;

пункт «1. Кушымта итеп бирелә торган Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.» пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Кушымта итеп бирелә торган Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.»;

Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм юкка чыгару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең күрсәтелгән боерык белән расланган административ регламентын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә)

**Рәис** **Ф.С. Батков**

Татарстан Республикасы
Биологик ресурслар
буенча дәүләт
комитетының 2018 елның
16 маендагы 124-од
номерлы боерыгы белән
расланган (Татарстан
Республикасы Биологик
ресурслар буенча дәүләт
комитетының 2025 елның
18 мартындагы 47-од
номерлы боерыгы
редакциясендә)

**Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

- Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.1. Гариза бирүчеләр – гражданлык законнары нигезендә гражданлык хокукый сәләтенә ия, белә торып җинаять кылган өчен юкка чыгарылмаган яисә алынмаган хөкем ителүе булмаган һәм Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының 2011 елның 30 июнендәге 568 номерлы боерыгы белән расланган аучылык минимумы таләпләре белән танышкан физик затлар (алга таба – аучылык минимумы, гариза бирүче).

Гариза бирүче исеменнән ышаныч кәгазе һәм аның шәхесен раслый торган документлар нигезендә ул вәкаләт биргән физик зат эш итә ала.

1.2. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә (хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан үткәрелә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән гариза бирүченең билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү) профильләштерү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы.

Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билеты бирү һәм гамәлдән чыгару.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган исеме.

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Комитет).

Дәүләт хезмәте Комитетның Административ һәм суд практикасы бүлеге (алга таба – Бүлек), Комитетның Хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм аеруча саклаулы табигать территорияләре өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге буенча район (районара) бүлекләре (алга таба – Комитетның район (районара) бүлеге) тарафыннан күрсәтелә .

Дәүләт хезмәте «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» Дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – КФҮ) аша күрсәтелә.

КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап гариза биргән очракта, КФҮнең гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итү мөмкинлеге бар
.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе:

1. Аучылык билеты бирү;

Аучылык билеты бирү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ булып «аучылык билетын, аучылык билеты формасын бирү һәм гамәлдән чыгару тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының 2024 елның 24 сентябрендәге 579 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча аучылык билеты тора (әлеге Регламентка 9 нчы кушымта). Гариза бирүчегә аучылык билеты бирү турында хәбәрнамә җибәрелә (әлеге Регламентка 7 нче кушымта);

2) аучылык билеты бирүдән баш тарту турында карар (әлеге Регламентка 5 нче кушымта);

3) аучылык билетын гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә (8 нче кушымта);

2.3.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе гариза бирүче тарафыннан Комитетта шәхсән, хәбәрнамә белән заказлы почта аша, КФҮ аша, электрон документ рәвешендә гариза бирүченең шәхси кабинетында Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http://gosuslugi.ru) (алга таба – Бердәм портал), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru) (алга таба –Республика порталы) алынырга мөмкин.

Комитетның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә, гариза бирүченең мөрәҗәгать итү ысулына карамастан, гариза бирүченең шәхси кабинетына Бердәм порталда яисә Республика порталында җибәрелә.

Гариза бирүче аучылык билетын кәгазьдә алу кирәклеген күрсәткән очракта, аучылык билеты гариза бирүчегә вәкаләтле орган тарафыннан шулай ук электрон документ рәвешендә бирелгән аучылык билеты белән бертигез юридик көчкә ия булган һәм «В» дәрәҗәсендәге якланган полиграфия продукциясе булган кәгазьдә дә аучылык билеты бирү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән бирелә.

Кәгазьдә язылган аучылык билетына вәкаләтле орган җитәкчесе яисә ул вәкаләт биргән вазыйфаи зат кул куя.

2.3.3.
Аучылык билеты реквизитлары:
серия, номер;
вәкаләтле органның исеме; вәкаләтле
вазыйфаи затның имзасы; бирү датасы
Аучылык билеты бирүдән баш тарту турында карар:
вәкаләтле органның исеме;
вәкаләтле вазыйфаи затның имзасы; дата,
номер.
Аучылык билетын гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә
реквизитлары: дата, номер;
вәкаләтле органның исеме; вәкаләтле
вазыйфаи затның имзасы.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты.

Гаризаны шәхсән, почта аша, КФҮ аша, Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинет аша биргәндә, аучылык билеты бирү өлешендә дәүләт хезмәте аучылык билеты бирү турында гариза теркәлгән көннән алып биш эш көне эчендә күрсәтелә.

Гаризаны шәхсән, почта аша, КФҮ аша, Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинет аша биргәндә, аучылык билетын гамәлдән чыгару өлешендә дәүләт хезмәте аучылык билетын гамәлдән чыгару турындагы гариза теркәлгән көннән алып бер эш көне эчендә күрсәтелә.

Гариза бирүче КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә, гариза һәм беркетелә торган документларны Комитетка Комитет белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда тапшыру тәэмин ителә. Дәүләт хезмәте күрсәтү процедурасын гамәлгә ашыру вакытына гаризаның КФҮдә булу вакыты һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен Комитеттан КФҮгә тапшыру вакыты кертелми.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр.

Бердәм порталда, Республика порталында, Комитет сайтында түбәндәгеләр урнаштырылган: а) дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

в) Комитет карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), шулай ук аның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затларына, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләренә, эшчеләренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

2.6.1. Аучылык билетын бирү өчен гариза бирүче түбәндәгеләрне тапшыра:

аучылык билеты бирү турында гариза (әлеге Регламентка 1 нче кушымта):

- кәгазь чыганактагы документ рәвешендә;

- 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләр кертү юлы белән тутырыла) Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә;

каралы-аклы яки төсле, түбәндәге таләпләргә туры килгән шәхси фото:

- 30x40 мм үлчәмле, йөз чалымы төгәл булган, катгый туры карап төшкән, баш киемсез;

- фотосурәттә йөзе гариза биргән көнне гариза бирүченең яшенә туры килергә тиеш, гариза бирүченең күзләре ачык булырга тиеш, чәчләре аларны капларга тиеш түгел;

- рәсемдә фотосурәткә төшүченең йөзенең барлык үзенчәлекләре күрсәтелергә тиеш;

- даими күзлек киеп йөрүче затлар өчен каралтмаган пыялалы күзлек белән сурәткә төшү мәҗбүри, кара күзлек белән сурәткә төшү яки күздә повязка булу бары медицина күрсәткечләре буенча гына рөхсәт ителә;

- форма киеме белән, өске кием белән, иякнең бер өлешен каплаган шарф бәйләп төшкән фотосурәт, шулай ук сурәттәге йөзнең тышкы кыяфәтен яхшырту яки аны сәнгатьчә эшкәртү максатларында редакцияләнгән фотосурәт тәкъдим итү рөхсәт ителми;

- гариза бирүченең дини ышанулары чит кешеләр алдында баш киемнәреннән башка күренергә рөхсәт итмәгән очракта, йөзләрен яшерми торган баш киеме белән төшкән сурәт тапшырыла;

- фотосурәтнең фоны ак, тигез, сызыкларсыз, тапларсыз, чит әйберләрнең сурәтләреннән һәм күләгәләрдән башка булырга тиеш;

Бердәм портал яисә Республика порталы аша электрон документ рәвешендә аучылык билеты бирү турында гариза биргән очракта, шәхси фотография аңа, түбәндәге таләпләрне үтәп, электрон файл рәвешендә беркетелә:

а) беркетелә торган файлда рәсемне кодлау (яздыру) форматы – JPEG яки JPEG 2000;

б) беркетелә торган фотосурәтнең минималь рөхсәт ителеше 450 dpi дан ким булырга тиеш түгел;

в) фотосурәт 24 бит лы төсле яссылыкта яки 8 бит лы монохром (кара һәм ак) яссылыкта ясалырга мөмкин;

г) беркетелә торган файлның максималь күләме 300 Кб тан (килобайт) артмаска тиеш.

шәхесне таныклый торган документ (почта аша, электрон формада гариза бирү очракларыннан тыш).

Гариза бирүче тарафыннан вәкаләт бирелгән зат өстәмә рәвештә аның вәкаләтен таныклый торган документ тапшыра.

Гариза Бердәм портал, Республика порталы аша җибәрелгән очракта, гариза бирүченең яисә гариза бирүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затның шәхесен таныклый торган документтагы белешмәләр бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (алга таба – ЕСИА) исәп язмасы расланганда тикшерелә.

Гариза бирүче аучылык билеты бирү турындагы гаризада түбәндәгеләрне күрсәтә:

а) мондый гариза бирелә торган вәкаләтле орган исеме;

б) гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

в) гариза бирүченең туган көне һәм урыны;

г) гариза бирүче белән элемтә гамәлгә ашырыла торган элемтә телефоны номеры, почта адресы һәм электрон почта адресы (булган очракта);

д) гариза бирүченең шәхесен таныклый торган төп документ мәгълүматлары;

е) гариза бирүченең тору урыны буенча теркәлүен раслый торган документ күрсәткечләре (аучылык билетын бирү турында гариза гариза бирүченең тору урыны буенча вәкаләтле органга җибәрелгән очракта);

ж) гариза бирүченең индивидуаль шәхси счетының иминият номеры (булган очракта);

Гариза бирүче өстәмә рәвештә гаризада түбәндәгеләрне күрсәтергә хокуклы:

а) үз милләтен;

б) ауны яшәвенең нигезе буларак тормышка ашыру турында мәгълүматлар.

в) аучылык билетына «Традицион яшәү рәвешен алып баруны тәэмин итү һәм традицион хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында аучылык шәхси кулланулны канәгатьләндерү өчен кирәкле аучылык ресурсларын аулау күләмендә ирекле (бернинди рөхсәтсез) гамәлгә ашырыла» дигән тамга кую кирәклеге турында мәгълүматны;

г) аучылык билетын кәгазьдә алу кирәклеге турында мәгълүмат.

Гариза бирүче аучылык билетын кәгазьдә алырга кирәклеген күрсәткән очракта, аучылык билетын бирү турындагы гаризада шулай ук аучылык билетын алуның түбәндәге ысулларының берсе күрсәтелә:

а) вәкаләтле органда шәхсән үзе;

б) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә шәхсән (килешү нигезендә)

в) тапшыру турында хәбәр итеп, заказлы почта аша.

2.6.2. Аучылык билетын гамәлдән чыгару өчен гариза бирүче түбәндәгеләрне тапшыра: аучылык билетын гамәлдән чыгару турында гариза (әлеге Регламентка ___ номерлы кушымта):

- кәгазь чыганактагы документ рәвешендә;

- 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (гаризаның электрон рәвешенә тиешле белешмәләр кертү юлы белән тутырыла) Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә;

- шәхесне таныклый торган документ (почта аша гариза бирү очракларыннан тыш, электрон формада).

Гариза бирүче тарафыннан вәкаләт бирелгән зат өстәмә рәвештә аның вәкаләтен таныклый торган документ тапшыра.

Гариза Бердәм портал, Республика порталы аша җибәрелгән очракта, гариза бирүченең яисә гариза бирүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затның шәхесен таныклый торган документтагы белешмәләр бердәм идентификация һәм аутентификация системасында исәп язмасы расланганда тикшерелә.

2.6.3. Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын гариза бирүче Комитетка яки **КФҮ гә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин.** Бланкның электрон формасы Комитетның рәсми сайтында (http://ojm.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Гариза һәм беркетеп бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсен кулланып тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

1) Комитетка шәхсән йә почта аша җибәрү юлы белән.

2) Республика порталы, Бердәм портал аша электрон документ рәвешендә.

Гаризаны Бердәм портал яисә Республика порталы аша җибәргәндә, гариза бирүче гариза биргән көнне Бердәм порталдагы яисә Республика порталындагы шәхси кабинетына һәм электрон почта аша гаризаның теркәлү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелгән, гариза җибәрелүен раслый торган хәбәрнамә ала.

Гариза һәм кирәкле документларны Бердәм портал яисә Республика порталы аша җибәргәндә, гариза бирүчеләр гаризага гади электрон имза куялар.

Гади электрон имза алу өчен, гариза бирүчегә ЕСИАда теркәлү (аутентификация) процедурасын үтәргә, шулай ук хисап язмасын стандарттан түбән булмаган дәрәҗәдә расларга кирәк.

3) кәгазь чыганакларда КФҮ аша.

2.6.4. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар:

1) гариза бирүченең аңлы рәвештә җинаять кылганы өчен үтәлмәгән яки алынмаган хөкем ителгәнлеге булу (булмау) турында белешмәләр (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

2) гариза бирүченең паспортының гамәлдә булуын раслау турында белешмәләр (электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәткәндә) – (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан).

Гариза бирүче гариза биргәндә, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек аша алырга мөмкин булган документларны мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле имзалары белән расланган электрон документлар рәвешендә мөстәкыйль тапшырырга хокуклы.

Гариза бирүче тарафыннан күрсәтелгән документларны тапшырмау гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза вәкаләтләренә хезмәт күрсәтү кермәгән дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына яки оешмага бирелгән;

2) тапшырылган документлар яки белешмәләр дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән вакытка үз көчен югалткан;

3) гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә тапшырылган документларда Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган текстта бетерү һәм төзәтү бар;

4) электрон рәвештә тапшырылган документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә кулланырга мөмкинлек бирми торган зыяннар бар;

5) гариза формасында, шул исәптән Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның интерактив формасында кырларны тулысынча тутырмау;

6) гариза бирүченең фотосы билгеләнгән таләпләргә туры килми яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен куллану рөхсәт итмәгән зыянны үз эченә ала;

7) 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларын үтәмәү ачыкланган.

8) хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы булмаган комплектын тапшыру (әлеге Регламентның 2.6.1, 2.6.2 пунктлары нигезендә).

2.7.2. Баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар әлеге Регламентка 3 нче кушымтада билгеләнгән форма нигезендә рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә имзалана һәм гариза бирүчегә кабул ителгән көнне Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинетына җибәрелә һәм гариза бирүче сайлавы буенча шәхсән, почта аша, КФҮгә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул иткән көнне җибәрелә.

2.7.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда, Республика порталында, Комитетның рәсми сайтында бастырылган дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган гаризаны һәм башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

2.8.
Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.8.2. Аучылык билетын бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

а) гариза бирүченең 2009 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 1 өлеше таләпләренә туры килмәве;

б) гариза бирүчегә аучылык билеты бирү турында дәүләт аучылык хуҗалыгы реестрында, әгәр андый билет 2009 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 8 өлешендә каралган нигезләр буенча гамәлдән чыгарылмаган булса, мәгълүмат булу.

2.8.3. Аучылык билетын гамәлдән чыгарудан баш тарту өчен нигезләр каралмаган.

2.8.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза Бердәм порталда, Республика порталында, Комитетның рәсми сайтында бастырып чыгарылган дәүләт хезмәтен күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.1 Гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргәндә һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, гариза бирүчене кабул итүне көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен дәүләт хезмәте күрсәтүгә чират билгеләнмәгән.

2.11. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризасын теркәү вакыты

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны теркәү барлык кирәкле документлар белән гариза Комитетка кергән көнне башкарыла.

Электрон рәвештә ял (бәйрәм) көнендә кергән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килә торган эш көнендә теркәлә.

Гариза һәм документларны **КФҮ** аша тапшырган очракта, гариза бирү көне итеп Комитетта гаризаны теркәү көне санала.

Республика порталы, Бердәм портал аша электрон рәвештә кергән гариза, Республика порталында, Бердәм порталда гаризаларны автомат рәвештә теркәү булмаган очракта, кергән көнне Комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр.

Дәүләт хезмәте Комитетның янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарында һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Көтү залларында (урынында) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге һәм аларны тутыру үрнәкләре белән мәгълүмати стендлар урнаштырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озатып йөртүче этләрдән файдаланучыларга, бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

биналарга һәм бүлмәләргә, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә каршылыксыз керү шартлары;

территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, биналарга һәм бүлмәгә керү һәм чыгу, транспорт чарасына, шул исәптән кресло-коляска кулланып утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе нык бозылган инвалидларны биналарда һәм бүлмәләрдә озатып йөрү һәм аларга ярдәм күрсәтү;

инвалидларның бинага, бүлмәләргә һәм дәүләт хезмәтләренә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртү чыганакларын, аларның тормыш эшчәнлегенең чикләнгәнлеген исәпкә алып урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле тавыш белән һәм күреп кабул ителә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайль рельефлы-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемне кертү;

йөртүче этне махсус укытуны раслый торган һәм «Йөртүче этне махсус укытуны раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә тапшырыла торган документы булганда бинага һәм бүлмәгә кертергә рөхсәт итү;

Комитетның парковкасында I, II төркем инвалидлар идарә итә торган транспорт чараларын һәм мондый инвалидларны һәм (яки) инвалид балаларны йөртә торган транспорт чараларын түләүсез куеп тору өчен урыннарның кимендә 10 проценты (ләкин бер урыннан да ким булмаган күләмдә) бүлеп бирелә. Әлеге пунктта күрсәтелгән парковка урыннарын, юл хәрәкәте кагыйдәләре белән каралган очраклардан тыш, башка транспорт чаралары биләмәскә тиеш;

Комитетның хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән беррәттән дәүләт хезмәте күрсәтүгә комачаулаучы каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.

2.13. Дәүләт хезмәтенең үтемлелеге һәм сыйфаты күрсәткечләре.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемлелеге күрсәткечләренә түбәндәгеләр керә:

биналарының җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкин булган зонада урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итә торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Комитетның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе, вакыты турында тулы мәгълүмат булу;

гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге;

инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәттән файдаланырга комачаулый торган, инвалидлар өчен биналардан файдалану уңайлылыгын тәэмин итүгә бәйле булмаган башка каршылыкларны җиңеп чыгуда дәүләт хезмәте күрсәтүче Комитет хезмәткәрләре тарафыннан ярдәм күрсәтү.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты күрсәткечләренә түбәндәгеләр керә:

документларны кабул итү һәм карау вакытын үтәү;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу вакытын үтәү;

Комитет белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозуга карата прецедентларның (нигезләнгән шикаятьләрнең) булмавы;

гариза бирүченең Комитет белгечләре белән хезмәттәшлеге саны:

турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тапшырганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә.

Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы территориясендә экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә. Комплекслы сорату аша КФҮдә дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкинлеге каралмаган.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Комитетта, Республика порталында, Бердәм порталда шәхси кабинетта, КФҮдә алынырга мөмкин.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә, шул исәптән күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте хакында белешмәләр бирү турында башка таләпләр.

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

2.14.3. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәткәндә, консультация бирүне, документлар кабул итү һәм бирүне КФҮ белгече башкара.

Гариза бирүче КФҮ аша мөрәҗәгать иткәндә, гариза һәм документларны гаризаны теркәү көненнән алып бер эш көне эчендә Комитетка тапшыру тәэмин ителә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, Комитет һәм КФҮнең үзара хезмәттәшлек тәртибе Комитет һәм КФҮ арасында төзелә торган үзара хезмәттәшлек турында килешү белән, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән үзара хезмәттәшлек тәртибе – КФҮнең эш регламенты белән җайга салына.

2.14.4. Гариза бирүче гаризаны электрон документ формасында җибәрә ала, аны рәсмиләштерү тәртибе «Дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәк булган гаризаларны һәм башка документларны электрон документлар рәвешендә рәсмиләштерү һәм тапшыру тәртибе турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 7 июлендәге 553 номерлы карары белән билгеләнгән һәм ул төгәл бер мәгънәле һәм яшерен мәгълүмат, шулай ук электрон рәвештә арадаш хәбәрләр һәм җавап мәгълүматлары җибәрү һәм алу мөмкинлеген тәэмин итә торган гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрләрне, шул исәптән «Интернет» челтәрен, Республика порталын, Бердәм порталны да кертеп (техник мөмкинлекләр булганда) файдаланып, шул исәптән 63-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә гади электрон имза кулланып тапшырыла.

Комитетка Республика порталыннан, Бердәм порталдан файдаланып, электрон документ рәвешендә кергән гаризаны теркәү, гариза бирүчегә аның гаризасын алу турында мәгълүматны үз эченә алган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны Комитетка тапшыру датасын күрсәтеп, электрон рәвештә хәбәрнамә формалаштыру һәм җибәрү Комитетка гариза кергән көнне автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

2.14.5. Күп функцияле үзәктә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре.

КФҮдә кабул итүгә гариза бирүчеләрне язу (алга таба – язылу) Бердәм портал, Республика порталы, КФҮнең элемтә үзәге телефоны аша башкарыла.

Гариза бирүчегә (гариза бирүче вәкиленә) кабул итү өчен теләсә кайсы буш датага һәм вакытка КФҮдә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә язылу мөмкинлеге бирелә.

Бердәм портал, Республика порталы аша алдан язылу өчен, гариза бирүчегә (гариза бирүченең вәкиленә) Система сората торган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта); телефон номеры;

электрон почта адресы (теләк буенча);

кабул итүнең теләгән көне һәм вакыты.

Гариза бирүче алдан язылганда хәбәр иткән белешмәләр гариза бирүченең шәхсән кабул иткәндә тапшырган документларына туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан яылып куйганда, гариза бирүчегә раслау талонын бастырып чыгару мөмкинлеге тәэмин ителә.

Әгәр гариза бирүче электрон почта адресын хәбәр итсә, күрсәтелгән адреска шулай ук, кабул итү вакыты һәм урыны датасын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылуны башкарганда, гариза бирүчегә алдан язылуның билгеләнгән кабул итү вакытыннан унбиш минут узгач, ул килмәгән очракта гамәлдән чыгарылуы турында мәҗбүри рәвештә хәбәр ителә.

Гариза бирүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан тыш башка гамәлләр кылуны, кабул итүнең максатын күрсәтүне, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакыт интервалы озынлыгын исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне бирүне таләп итү тыела.

Алдан язылу булмау гариза бирүчене чират тәртибендә кабул итүгә комачауламый.

2.14.6. Күп функцияле үзәктә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре.

2.14.6.1. Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәткәндә, гариза бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 72 пункты нигезендә электрон образлары элек таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

3) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында электрон рәвештә бирелгән гаризаларны карау барышы турында белешмәләр алырга;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга хокуклы;

6) Комитетның, шулай ук аның вазыйфаи затларының карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) карата Бердәм портал, Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кылынган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша. федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша шикаять бирергә.

2.14.6.2. Гаризаны формалаштыру башка формада өстәмә гариза бирү гаризаның электрон формасын Бердәм порталда, Республика порталында тутыру юлы белән башкарыла (башка формада өстәмә гариза бирү таләп ителми).

2.14.6.3. Гариза язганда, түбәндәге мөмкинлекләр бирелә:

1) гаризаны һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны күчереп алу һәм саклап калу мөмкинлеге;

2) электрон гариза формасының күчермәсен кәгазьдә бастыру мөмкинлеге;

3) элек электрон гариза формасына кертелгән кыйммәтләрне кулланучы теләге белән теләсә кайсы вакытта, шул исәптән кертү хаталары килеп чыкканда һәм белдерүнең электрон формасына кыйммәтләрне яңадан кертү өчен кире кайтарганда саклау;

4) гариза бирүче ЕСИАда урнаштырылган мәгълүматны һәм, ЕСИАда булмаган мәгълүматларга кагылышлы өлештә Бердәм порталда, Республика порталында басылган мәгълүматларны кулланып мәгълүматны керткәнче, гаризаның электрон формасы кырын тутыру;

5) элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча, гаризаның электрон формасын тутыруның теләсә кайсы этабына кайту мөмкинлеге;

6) гариза бирүченең үзенең элек биргән гаризаларына кимендә бер эчендә, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризаларга кимендә өч ай эчендә керү мөмкинлеге.

2.14.7. Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат мәгълүмати стендларда һәм Комитетның рәсми сайтында урнаштырыла.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү вакытлары

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда һәм төзелгән реестр язмаларында җибәрелгән басмадагы хаталарны һәм хаталарны төзәтү өчен кирәкле дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары исемлеге.

Дәүләт хезмәте, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда һәм төзелгән реестр язмаларында җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү бердәм вариантта башкарыла һәм дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары, гариза бирүчеләр категорияләре, түләү күләме һәм тәртибе, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге белән; дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә барлыкка килгән документлар һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләр белән аерылып торган дәүләт хезмәте күрсәтүнең аерым сценарийлары юк.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча бирелгән документның дубликатын бирү вариантлары исемлеге, шул исәптән мондый дубликат бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре буенча документ дубликатын бирү бердәм вариантта башкарыла һәм бирү сроклары, гариза бирүчеләр категорияләре, түләү күләме һәм тәртибе, дубликат бирү өчен кирәкле документлар исемлеге белән; дубликат бирү нәтиҗәсендә барлыкка килгән документлар һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләр белән аерылып торган сценарийлары юк.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча гариза бирүчегә бирелгән документның дубликатын бирүдән баш тарту өчен нигез юк.

3.3. Гариза бирүчене профильләштерүнең административ процедурасы тасвирламасы Гариза бирүчене профильләштерү процедурасы башкарылмый.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдәге гамәлләр тәртибен тасвирлау

3.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү, шул исәптән, гаризаны рәсмиләштерүдә ярдәм күрсәтү;

2) аучылык билеты бирү:

а) аучылык билеты бирү турында гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

б) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратуларны формалаштыру һәм җибәрү;

в) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен әзерләү; г) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен бирү;

3) аучылык билетын гамәлдән чыгару:

а) аучылык билетын гамәлдән чыгару турында гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү.

б) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен әзерләү; в) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен бирү;

4) җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү:

а) җибәрелгән басмадагы хаталар һәм хаталарны төзәтү турында гариза кабул итү һәм теркәү (тәкъдим ителә торган форма әлеге Регламентка 3 нче кушымтада китерелгән);

б) дәүләт хезмәте күрсәтүнең яңадан рәсмиләштерелгән нәтиҗәләрен әзерләү;

в) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүнең яңадан рәсмиләштерелгән нәтиҗәләрен бирү;

3.5. Гариза бирүчегә консультация бирү, шул исәптән, гаризаны рәсмиләштерүдә ярдәм күрсәтү.

Вазыйфаи регламентлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү эшен оештыру өчен җаваплы Бүлек белгече яки Комитетның район (районара) бүлеге башлыгы (җитәкчесе) (алга таба – Комитет белгече) гариза бирүчегә, шул исәптән документлар формасы һәм дәүләт хезмәтен алу өчен башка мәсьәләләр буенча консультация бирүне гамәлгә ашыралар. Кирәк булса, Комитет белгече гариза бирүчегә шул исәптән гаризаны рәсмиләштерү өлешендә дә ярдәм итә.

Гариза бирүче Бүлеккә яисә Комитетның район (районара) бүлегенә шәхсән, телефон аша һәм (яки) электрон почта аша (e-mail: ojm@tatar.ru) электрон хәбәр рәвешендә, почта аша кәгазь чыганакта, Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Рәсми порталының интернет-кабул итү бүлмәсе аша (http://ojm.tatarstan.ru) дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында, шул исәптән гаризаны рәсмиләштерүдә консультация алу өчен мөрәҗәгать итә.

Гариза бирүче КФҮгә дәүләт хезмәте күрсәтүне алу тәртибе турында консультация алу өчен шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итә ала.

КФҮ хезмәткәре гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтен алу өчен тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча хәбәр итә һәм, кирәк булганда, гариза бланкын тутырырга ярдәм итә.

Гариза бирүче КФҮ сайтыннан (http://mfc16.tatarstan.ru/) ирекле файдалану юлы белән дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат ала ала.

Шулай ук Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм вакыты турында Республика порталында, Бердәм порталда консультация алырга хокуклы.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә консультация бирү, ярдәм күрсәтү, шул исәптән гаризаны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.6. Аучылык билетын бирү турында гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү.

3.6.1.

2.6.1 Гариза бирүче аучылык билеты бирү турында гаризаны әлеге Регламентның пункты нигезендә документлар шәхсән Бүлеккә яки Комитетның район (районара) бүлегенә тапшыра яисә аны почта аша җибәрә, КФҮ аша яисә электрон документ рәвешендә Бердәм портал аша, Республика порталы аша гариза бирә

Гариза бирүче, гаризаны электрон формада Бердәм портал яисә Республика порталы аша тапшырган очракта, түбәндәге гамәлләрне башкара:

Бердәм порталда яки Республика порталында авторизация үтә;

Бердәм порталда яисә Республика Порталында электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яисә документларның электрон образларын (кирәк булганда) электрон гариза формасына беркетә;

электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтүнең шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга куя);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамганы куя);

тутырылган электрон гариза җибәрә (электрон гариза формасында тиешле төймәгә баса);

электрон гариза, 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләренә туры китереп (гади электрон имза һәм (яисә) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалана;

электрон гариза җибәрү турында хәбәрнамә ала.

КФҮ аша гариза биргән очракта:

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза бирә һәм документларны әлеге Регламентның 2.6.1 пункты нигезендә КФҮгә тапшыра.

Гаризалар кабул итүче **КФҮ** хезмәткәре КФҮнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, **КФҮ** белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, КФҮ белгече гариза бирүченең кабул ителгән һәм теркәлгән документларын КФҮнең эш регламентында билгеләнгән тәртиптә Комитетка җибәрә. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Комитет белән КФҮнең үзара хезмәттәшлеге тәртибе Комитет белән КФҮ арасында төзелә торган килешү белән, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән хезмәттәшлек тәртибе – КФҮнең эш регламенты белән җайга салына.

Регламентның әлеге пункты белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла. КФҮ аша гариза биргән очракта, әлеге пункт тарафыннан билгеләнә торган процедуралар КФҮнең эш регламенты һәм Комитет белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешү белән билгеләнгән вакытта, ләкин **КФҮ**дә гаризаны теркәгәннең икенче эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Комитетка җибәрелгән гариза яки документлар кабул итүдән баш тарту.

3.6.2. Бүлек белгече яки Комитетның район (районара) бүлеге башлыгы (җитәкчесе) түбәндәгеләрне башкара:

әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларның булу-булмавын тикшерү.

кергән документларны, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан электрон формада кушып бирелгән документларны һәм документларның электрон образларын өйрәнә;

электрон документ образларының комплектлылыгын, укылуын тикшерә;
Бердәм порталга яисә Республика порталына мөрәҗәгать итеп, электрон имзаның чынбарлык шартлары үтәлешен тикшерә (гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документларның электрон образлары тапшырылган очракта);

гариза бирүче вәкаләт биргән зат буларак эш итүче гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерү.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигез булган очракта, Бүлек белгече яки Комитетның район (районара) бүлеге башлыгы (җитәкчесе) түбәндәгеләрне башкара:

шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гаризаны теркәүдән баш тарту өчен нигезләрнең булуы турында хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту сәбәбен күрсәтеп, аңа документларны кире кайтара. Гариза бирүче таләбе буенча баш тарту турындагы карар язма рәвештә рәсмиләштерелә;

почта аша йә электрон рәвештә гариза биргәндә, хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карарны (әлеге Регламентка 4 нче кушымта) почта адресына яисә Бердәм портал, Республика порталы аша һәм гаризада күрсәтелгән электрон адреска җибәрә. 2.7.1 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Комитетның бүлек белгече яисә район (районара) бүлеге башлыгы (җитәкчесе) гаризаларны кабул итә һәм теркәү журналында терки.

Регламентның әлеге пункты белән билгеләнә торган процедура Комитетка гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гаризаларны теркәү журналында теркәү язмасы, гариза бирүчегә документлар кабул итү датасы, бирелгән керү датасы, дәүләт хезмәте күрсәтү датасы турындагы тамга белән гариза күчермәсен тапшыру яки җибәрү яки, баш тарту сәбәпләрен нигезләп, гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.7. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек юлы белән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара сорату язу һәм җибәрү.

3.7.1. Сорату җибәрү өчен нигез булып, дәүләт хезмәте күрсәтү турында теркәлгән гариза тора.

3.7.2. Бүлек белгече яки Комитетның район (районара) бүлеге башлыгы (җитәкчесе) Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон формада соратулар формалаштыра һәм җибәрә:

3.7.3. гариза бирүченең аңлы рәвештә җинаять кылганы өчен үтәлмәгән яки алынмаган хөкем ителгәнлеге булу (булмау) турында белешмәләр тапшыру турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына);

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына гариза бирүче паспортының дөреслеген раслау турында белешмәләр бирү хакында.

Ведомствоара мәгълүмати сорату, гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына җибәрелгән соратулар.

3.7.4.

2.6.4

Ведомствоара соратулар буенча әлеге Регламентның 2.6.4 пунктында каралган мәгълүматлар бу документлар электрон формада алар карамагында булган органнар тарафыннан «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кагыйдәләре, шул исәптән Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруның тәкъдим ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә тиешле ведомствоара сорату җибәрелгәннән соң 48 сәгатьтән дә соңга калмыйча бирелә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазьдә башкарылырга мөмкин:

1) соратыла торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә электрон ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра алмаганда;

2) ведомствоара сорату җибәргәндә, кәгазьдә документларның төп нөсхәсен тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазьдә гамәлгә ашырылса,әлеге Регламентның 2.6.4 пунктында каралган белешмәләр күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документлар булган органнар тарафыннан тапшырыла.

210-ФЗ номерлы Федераль законның 72 статьясындагы 3 өлеше нигезендә ведомствоара соратуларга җавап әзерләү һәм җибәрү вакыты ведомствоара сорату кергән көннән биш эш көненнән артып китә алмый.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай законнарны һәм гариза бирүченең хокукларын бозуга юл куймый торган карарлар кабул итү тора.

Процедураның нәтиҗәсе: Комитетка җибәрелгән, соратуларга җавап нәтиҗәсе булган мәгълүматлар (документлар) яки баш тарту турындагы хәбәрнамәләр.

3.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен – аучылык билеты бирү (бирүдән баш тарту) турындагы карарны әзерләү.

3.8.1. Бүлек белгече яки Комитетның район (районара) бүлеге башлыгы (җитәкчесе) әлеге Регламентның 2.6.1 пункты нигезендә гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документлар һәм эчке эшләр органнарының җавабы нигезендә аучылык билетын бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итә.

Регламентның әлеге пункты белән билгеләнә торган процедура ведомствоара соратуларга җавап алганнан соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: башкаруга җибәрелгән документлар.

3.8.2. Комитетның бүлек белгече яки район (районара) бүлеге башлыгы (җитәкчесе), әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында каралган нигезләр булганда, ведомствоара соратуларга җавап алган көннән соң бер эш көне эчендә аучылык билеты бирүдән баш тарту турында карар кабул итәләр.

3.8.3. Бүлек белгече дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын әзерли (әлеге Регламентка 5 нче кушымта).

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карар проекты документлар белән Бүлек башлыгына килештерүгә җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура ведомствоара соратуларга җавап алганнан соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерүгә җибәрелгән документлар белән хезмәт күрсәтүдән баш тарту турындагы карар проекты.

3.8.5. Бүлек башлыгы дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карар проектын килештерә һәм имзалый.

Регламентның әлеге пункты белән билгеләнә торган процедура әлеге Регламентта каралган алдагы процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында имзаланган карар.

3.8.6. Бүлек белгече дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карарны терки һәм гариза бирүчегә шәхсән, почта аша яки Бердәм портал аша, Республика порталы аша, **КФҮ аша җибәрә.** Тәкъдим ителгән документларның күчермәләре Бүлектә саклана.

Регламентның әлеге пункты белән билгеләнә торган процедура әлеге Регламентта каралган алдагы процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында имзаланган һәм җибәрелгән карар.

3.8.7. Комитетның район (районара) бүлеге башлыгы (җитәкчесе) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карарны әзерли, имзалый, терки һәм гариза бирүчегә шәхсән, почта аша яки Бердәм портал аша, Республика порталы аша, **КФҮгә җибәрә.** Тәкъдим ителгән документларның күчермәләре Бүлеккә саклау өчен тапшырыла.

Регламентның әлеге пункты белән билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.8.2 пунктында каралган процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында имзаланган һәм җибәрелгән карар.

3.9. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү – гариза бирүчегә аучылык билеты бирү.

3.9.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында каралган нигезләр булмаганда, бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

аучылык билеты бланкын тутыра, гариза бирүченең фотосурәтен ябыштыра һәм Комитет рәисенә яки аның урынбасарына, алар булмаганда – Хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм аеруча саклаулы табигать территорияләре өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге идарәсе башлыгына (алга таба – Идарә башлыгы) имзага җибәрә;

мәгълүматларны дәүләт аучылык хуҗалыгы реестрына (алга таба – Реестр) кертә;

Реестрга мәгълүматлар кертү турында хәбәрнамә (алга таба – мәгълүматлар кертү турында хәбәрнамә) (әлеге Регламентка 6 нчы кушымта) һәм аучылык билеты бирү турында хәбәрнамә (7 нче кушымта) проектларын әзерли, аларны Бүлек башлыгына килештерүгә җибәрә.

3.9.2. Комитет рәисе (рәис урынбасары, Идарә башлыгы) аучылык билеты бланкын имзалый.

3.9.3. Бүлек башлыгы мәгълүматлар кертү турында һәм аучылык билеты бирү турында хәбәрнамәләр проектын имзалый.

Әлеге Регламентның 3.9.1 – 3.9.3 пунктлары белән билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентта каралган алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүматлар кертү турында һәм аучылык билеты бирү турында имзаланган хәбәрнамәләр.

3.9.4. Бүлек белгече мәгълүматлар кертү турында хәбәрнамә һәм аучылык билеты бирү турында хәбәрнамәне терки һәм аны гариза бирүчегә җибәрә.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән һәм гариза бирүчегә җибәрелгән мәгълүматлар кертү турында хәбәрнамә һәм аучылык билеты бирү турында хәбәрнамә.

3.9.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен, әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында каралган нигезләр булмаганда, Комитетның район (районара) бүлеге башлыгы (җитәкчесе) аучылык билеты бланкын тутыра,гариза бирүченең фотографиясен ябыштыра һәм

аучылык билетына кул куя; реестрга белешмәләр кертә;

мәгълүматлар кертү турында хәбәрнамәнең һәм аучылык билеты бирү турында хәбәрнамәнең проектын әзерли, имзалый.

мәгълүматлар кертү турында хәбәрнамәне һәм аучылык билеты бирү турында хәбәрнамәне терки, гариза бирүчегә җибәрә.

3.9.6. Гариза бирүче Бердәм портал яки Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, мәгълүматлар кертү һәм аучылык билетын бирү турында хәбәрнамәне кертү турында хәбәрнамә гариза бирүчегә шәхси кабинетына җибәрелә.

3.9.4 – 3.9.6 пунктлары белән билгеләнә торган процедуралар аучылык билеты бланкына кул куелганнан соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: аучылык билетының тутырылган бланкы, Реестрга кертелгән мәгълүматлар, почта яисә Бердәм портал, Республика порталы аша, КФҮ аша гариза бирүчегә җибәрелгән мәгълүматлар кертү турында хәбәрнамә һәм аучылык билеты бирү турында хәбәрнамә.

3.9.7. Бүлек белгече яки Комитетның район (районара) бүлеге башлыгы (җитәкчесе) гариза бирүчегә ул күрсәткән ысул белән аучылык билеты тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән аучылык билеты.

3.9.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризада дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен КФҮ аша бирү турында күрсәтмә булганда, Комитет документларны, гариза бирүчегә бирү өчен, КФҮгә тапшыра. Мондый документларны КФҮгә тапшыру тәртибе һәм вакыты алар арасында төзелгән килешү нигезендә билгеләнә.

3.9.9. Аучылык билеты электрон документ рәвешендәге хәбәрнамә, гариза бирүченең мөрәҗәгать итү ысулына карамастан, Бердәм порталда, Республика порталында гариза бирүченең шәхси кабинетына җибәрелә.

3.10. Аучылык билетын гамәлдән чыгару.

3.10.1. Гариза бирүче аучылык билетын гамәлдән чыгару турында гаризаны әлеге Регламентның 2.6.2 пункты нигезендә документлар белән Комитетның бүлегенә яисә район (районара) бүлегенә шәхсән үзе бирә, яисә гаризаны Бердәм портал, Республика порталы, КФҮ аша электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә бирә, почта аша җибәрә.

3.10.2. Гариза бирүче, гаризаны электрон формада Бердәм портал яисә Республика порталы аша тапшырган очракта, түбәндәге гамәлләрне башкара:

Бердәм порталда яки Республика порталында авторизация үтә; Бердәм

порталда яисә Республика Порталында электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яисә документларның электрон образларын (кирәк булганда) электрон гариза формасына беркетә;

дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза рәвешендә ризалык турында тиешле тамга куя);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамганы куя);

тутырылган электрон гариза җибәрә (электрон гариза формасында тиешле төймәгә баса);

электрон гариза, 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләренә туры китереп (гади электрон имза һәм (яисә) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалана;

электрон гариза җибәрү турында хәбәрнамә ала. КФҮ аша

гариза биргән очракта:

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза бирә һәм документларны әлеге Регламентның 2.6.2 пункты нигезендә КФҮгә тапшыра.

Гаризалар кабул итүче КФҮ хезмәткәре КФҮнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, КФҮ белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, КФҮ белгече гариза бирүченең кабул ителгән һәм теркәлгән документларын КФҮнең эш регламентында билгеләнгән тәртиптә Комитетка җибәрә. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Комитет белән КФҮнең үзара хезмәттәшлеге тәртибе Комитет белән КФҮ арасында төзелә торган килешү белән, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән хезмәттәшлек тәртибе – КФҮнең эш регламенты белән җайга салына.

Регламентның әлеге пункты белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла. КФҮ аша гариза биргән очракта, әлеге пункт тарафыннан билгеләнә торган процедуралар КФҮнең эш регламенты һәм Комитет белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешү белән билгеләнгән вакытта, ләкин КФҮдә гаризаны теркәгәннең икенче эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Комитетка җибәрелгән гариза яки документлар кабул итүдән баш тарту.

3.10.3. Комитетның бүлек белгече яисә район (районара) бүлеге начальнигы (җитәкчесе) :

әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында күрсәтелгән документларның булу-булмавын тикшерә;

кергән документларны, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан электрон формада кушып бирелгән документларны һәм документларның электрон образларын өйрәнә;

электрон документ образларының комплектлылыгын, укылуын тикшерә; Бердәм порталга яисә Республика порталына мөрәҗәгать итеп, электрон имзаның чынбарлык шартлары үтәлешен тикшерә (гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документларның электрон образлары тапшырылган очракта);

гариза бирүче вәкаләт биргән зат буларак эш итүче гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерү.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигез булган очракта, Бүлек белгече яки Комитетның район (районара) бүлеге башлыгы (җитәкчесе) түбәндәгеләрне башкара:

шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гаризаны теркәүдән баш тарту өчен нигезләрнең булуы турында хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту сәбәбен күрсәтеп, аңа документларны кире кайтара. Гариза бирүче таләбе буенча баш тарту турындагы карар язма рәвештә рәсмиләштерелә;

почта аша йә электрон рәвештә гариза биргәндә, хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карарны (әлеге Регламентка 4 нче кушымта) почта адресына яисә Бердәм портал, Республика порталы аша һәм гаризада күрсәтелгән электрон адреска җибәрә.

2.7.1 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Комитетның бүлек белгече яисә район (районара) бүлеге башлыгы (җитәкчесе) гаризаларны кабул итә һәм теркәү журналында терки.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза яки гаризаны кабул итүдән баш тарту.

3.10.4. Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

аучылык билетын гамәлдән чыгару турында Реестрга мәгълүматлар кертә;

белешмәләр кертү турында хәбәрнамә проектын, аучылык билетын гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә (әлеге Регламентка 6 нчы кушымта) әзерли һәм аларны, имзалау өчен, Бүлек башлыгына җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: Реестрга кертелгән мәгълүматлар һәм Бүлек башлыгына имза салырга җибәрелгән мәгълүматлар кертү турында хәбәрнамә проекты, аучылык билетын гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә проекты.

3.10.5. Комитетның район (районара) бүлеге башлыгы (җитәкчесе) түбәндәгеләрне башкара:

аучылык билетын гамәлдән чыгару турында Реестрга мәгълүматлар кертә;

мәгълүматлар кертү турында хәбәрнамә проектын, аучылык билетын гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә проектын әзерли һәм аларны имзалый.

Процедураның нәтиҗәсе: Реестрга кертелгән мәгълүматлар һәм имза салынган мәгълүматлар кертү турында хәбәрнамә проекты, аучылык билетын гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә проекты.

3.10.6. Бүлек башлыгы мәгълүматлар кертү турында хәбәрнамә проектын һәм аучылык билетын гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә проектын имзалый. Имзаланган мәгълүматлар кертү турындагы хәбәрнамәне, аучылык билетын гамәлдән чыгару турында хәбәрнамәне Бүлек башлыгы Бүлек белгеченә җибәрә.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүматлар кертү турында һәм аучылык билеты бирү турында имзаланган хәбәрнамәләр.

3.10.7. Бүлек белгече белешмәләр кертү турында хәбәрнамәне, аучылык билетын гамәлдән чыгару турында хәбәрнамәне терки һәм аны гариза бирүчегә шәхсән тапшыра, заказлы почта аша хәбәрнамә белән, КФҮ аша, шулай ук электрон документ рәвешендә бердәм порталда яисә Республика порталында гариза бирүченең шәхси кабинетына җибәрә.

Аучылык билетын гамәлдән чыгару турында электрон документ рәвешендәге хәбәрнамә, гариза бирүченең мөрәҗәгать итү ысулына карамастан, Бердәм порталда, Республика порталында гариза бирүченең шәхси кабинетына җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән һәм гариза бирүчегәҗибәрелгән белешмәләр кертү турында хәбәрнамә, аучылык билетын гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә, гариза бирүче Бердәм портал яисә Республика порталыннан файдаланып гариза биргәндә, гариза бирүченең шәхси кабинетына җибәрү.

3.10.8. Гариза бирүче аучылык билетын кире кайтарганда, аны гамәлдән чыгару турында гариза биргәннән соң, аучылык билетында аны гамәлдән чыгару турында тамга ясала.

3.11. Җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү.

Дәүләт хезмәтенүрсәтү нәтиҗәсен яңадан рәсмиләштерү гариза бирүчегә бирелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә җибәрелгән техник хаталарны бетерүгә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

Аучылык билетын бирү буенча дәүләт хезмәте нәтиҗәсен яңадан рәсмиләштерү теркәлгән гариза нигезендә, аңа гариза бирүчегә бирелгән техник хатасы булган дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен теркәп гамәлгә ашырыла.

Җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү турында гариза Комитетка шәхсән, почта аша, КФҮ аша, Бердәм портал, Республика порталы ярдәмендә бирелә.

3.11.1. КФҮ аша биргәндә, гариза бирүче Комитет, Комитетның район (районара) бүлеге тарафыннан бирелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендәге хаталарын төзәтү турында гариза юллый.

Гаризалар кабул итүче КФҮ хезмәткәре КФҮнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

КФҮ хезмәткәре Комитетка, Комитетның район (районара) бүлегенә җибәрелгән басма хаталар һәм хаталарны төзәтү турында Комитет белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, ләкин КФҮдә гаризаны теркәгән көннән соңгы эш көненнән дә калмыйча, гариза җибәрә.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар КФҮнең эш регламенты белән билгеләнгән вакытта башкарыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе: җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.11.2. Бүлек белгече яки Комитетның район (районара) бүлеге башлыгы (җитәкчесе) түбәндәгеләрне башкаралар:

гаризаны кабул итү һәм теркәү;

документларны кабул итү датасы турында тамга, бирелгән керү номеры белән гариза күчермәсен гариза бирүчегә тапшыру яки почта аша яисә электрон почта аша (аның теләге буенча) җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән гариза.

3.11.3. Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кабат рәсмиләштерә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен яңадан рәсмиләштерү турында гариза бирүчегә хат проектын әзерли һәм, килештерү өчен, Бүлек башлыгына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Бүлек белгеченә башкару өчен гариза җибәргәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бүлек башлыгына килештерү өчен җибәрелгән дәүләт хезмәте күрсәтүнең яңадан рәсмиләштерелгән нәтиҗәсе, хат проекты.

3.11.4. Комитетның район (районара) бүлеге башлыгы (җитәкчесе) түбәндәгеләрне башкара:

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кабат рәсмиләштерә;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен яңадан рәсмиләштерү турында гариза бирүчегә хат проектын әзерли һәм аңа имза сала;

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен яңадан рәсмиләштерү турында хат җибәрә;

яңадан рәсмиләштерелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен шәхсән йә гаризада күрсәтелгән ысул белән гариза бирүчегә җибәрә;

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар аучылык билеты бланкына имза салынганнан соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән аучылык билеты.

3.11.5. Бүлек башлыгы дәүләт хезмәте күрсәтүнең әзерләнгән нәтиҗәсенең дөреслеген тикшерә, хат проектын килештерә һәм аны Комитет рәисенә имзалау өчен җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Бүлек башлыгына дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе һәм хат проекты килештерүгә кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Комитет рәисенә имзага җибәрелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре һәм хат проекты.

3.11.6. Комитет рәисе Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе белән бергә хат проектына кул куя һәм бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Бүлек башлыгыннан хат проекты кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерелгән хат проекты, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

3.11.7.

Бүлек белгече Комитет рәисе имзалаган хатны терки, ул дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе белән бергә гариза бирүчегә яисә аның ышанычлы затына (ышанычнамә булганда) расписка белән бирелә. Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза бирүче килгән көннән алып бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирчегә бирелгән (җибәрелгән) хат һәм төзәтелгән техник хата белән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

3.12. Аучылык билетының кабат нөсхәсен (дубликатын) бирү.

3.12.1. Аучылык билетының кабат нөсхәсен (дубликатын) бирү турында гаризаны гариза бирүче (вәкил) Комитетка шәхсән үзе бирә.

3.12.2. Комитетның бүлек белгече яисә район (районара) бүлеге башлыгы (җитәкчесе) кабат нөсхә (дубликат) бирү турында гаризаны кабул итә, гаризаны билгеләнгән тәртиптә терки.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.12.3. Аучылык билетының кабат нөсхәсен (дубликатын) бирүне сорап мөрәҗәгать иткәндә, документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат гариза бирүчегә вәкаләтле вазыйфаи затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган аучылык билетының кабат нөсхәсен (дубликатын) бирә. Гариза бирүченең таләбе буенча аңа электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе белән бергә аңа электрон документның нөсхәсе аны алынма мәгълүмат чыганагына язып кую яисә электрон документның нөсхәсен электрон почта аша мөрәҗәгать итүче адресына җибәрү юлы белән бирелә.

Административ процедураны үтәү нәтиҗәсе булып, гариза бирүчегә аучылык билетының кабат нөсхәсен (дубликатын) бирү тора

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

## 4. Административ регламентның үтәлешен тикшереп тору формалары

4.1. Җаваплы вазыйфаи затларның әлеге Регламент нигезләмәләрен, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларны үтәвен һәм башкарылуын, шулай ук аларның карарлар кабул итүен агымдагы тикшереп тору комитет рәисе тарафыннан, ул булмаганда, аның вазыйфаларын башкаручы зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Административ регламентның үтәлешен контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүне, дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләрне карау, карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формаларына түбәндәге тикшерүләрне үткәрү керә:

эш башкаруны алып бару;

документларны карау нәтиҗәләренең законнар (әлеге Регламент) таләпләренә туры килүе;

документларны кабул итү вакытын һәм тәртибен үтәү;

дәүләт хезмәте күрсәткәндә нәтиҗәләр бирү вакытын һәм тәртибен үтәү.

Тикшерүләр үткәрү ешлыгы планлы (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) характерда була.

4.3. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланганда, гаепле дип танылган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Административ регламентны башкаруны гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәткәндә Комитет эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

**5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1' өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, эшчеләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе**

5.1. Гариза бирүчеләр Комитетның, Комитетның вазыйфаи затының яисә Комитетның дәүләт граждан хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) Комитетка шикаять бирергә хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә Комитет карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

КФҮ хезмәткәрләренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр КФҮ җитәкчесенә бирелә, КФҮнең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр КФҮне гамәлгә куючыга бирелә.

5.2. Гариза бирүче шул исәптән түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) Дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратуны, 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән соратуны теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын бозу;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документларны яки мәгълүматны бирүне яисә гамәлләр башкаруны таләп итү;

4) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуның нигезләре каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Комитетның, аның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда алар тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы йә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозу;

8) дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яисә тәртибен бозу;

9) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуның нигезләре каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

10) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә аларның булмавы һәм (яки) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документлар яисә мәгълүмат таләп итү.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, Комитетның рәсми сайты (http://ojm.tatarstan.ru), Республика порталы (http://uslugi.tatarstan.ru), Бердәм портал (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә алынырга мөмкин.

КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, «Интернет» челтәрен, КФҮнең рәсми сайтын (http://mfc16.tatarstan.ru/), Республика порталын (http://uslugi.tatarstan.ru), Бердәм порталны (http://www.gosuslugi.ru) кулланып җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә алынырга мөмкин.

5.4. Шикаять түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган Комитетның, Комитетның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең, КФҮнең, аның җитәкчесенең яисә хезмәткәренең исеме;

гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр яки гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номер(-лар)ы, гариза бирүчегә җавап юлланырга тиешле электрон почта адрес(-лар)ы (булган очракта) һәм почта адресы;

Комитетның, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең шикаять бирелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

Комитетның, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең карары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән гариза бирүче килешми торган дәлилләр.

5.5. Гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булганда), йә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаять аның кергән көненнән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгәннән соң 15 эш көне эчендә. Комитетның, Комитетның вазыйфаи затының, КФҮнең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1' өлешендә каралган оешмаларның гариза бирүчедән документларны кабул итүдән йә җибәрелгән басмадагы хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына карата яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта шикаять белдерелгән очракта – аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басмадагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән түләү алу каралмаган очракларда алынган акчаны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә җавапта, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында, Комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм гариза бирүчегә дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында башкарырга кирәк булган алдагы гамәлләре турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип табылган очракта, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат китерелә.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләтле вазыйфаи зат, хезмәткәр, булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.

5.9. Комитет карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), шулай ук аның вазыйфаи затларына, йә дәүләт хезмәткәрләренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү белән бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җайга салына.

Татарстан
Республикасы Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитетының Аучылык билетын
бирү һәм гамәлдән чыгару буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына 1 нче кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар
буенча дәүләт комитетына
гражданнан_____________
(Ф.И.А.) (атасының исеме – булганда)
адрес
яшәү адресы ______________

Туган көне һәм урыны
______________________________

тел.______________________________________________
электрон почта адресы (булган очракта)
________________________________________
паспорт мәгълүматлары __
________________________________________
СНИЛС ____________
булган очракта

Аучылык билеты бирү турында гариза

Миңа аучылык билеты бирүегезне сорыйм.
Аучылык минимумы таләпләре белән таныштым.
Гариза бирүченең тору урыны буенча теркәлүен раслый торган документ мәгълүматлары
________________________________________________
Гариза бирүче теләге буенча башка мәгълүмат:
а) гариза бирүченең милләте _______________________
б) үз яшәешенең нигезе буларак аучылыкны гамәлгә ашыру турында белешмәләр

________________________________________________
в) аучылык билетына тамга куярга кирәклеге турында мәгълүмат:
«Традицион яшәү рәвешен алып баруны тәэмин итү һәм традицион хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында аучылык шәхси куллануны канәгатьләндерү өчен кирәкле аучылык ресурсларын аулау күләмендә ирекле (бернинди рөхсәтсез) гамәлгә ашырыла»
________________________________________________
г) аучылык билетын кәгазьдә алу кирәклеге турында мәгълүмат __________
________________________________________________
«     »________20   ел          /___________
(гариза бирүченең имзасы) / (имзаның расшифровкасы)

Татарстан
Республикасы Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитетының Аучылык билетын
бирү һәм гамәлдән чыгару буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына 2 нче кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар
буенча дәүләт комитетына

гражданнан _________ _ _ _ _ _ _ _ _
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)
______________________________________
Аучылык билетының хисап сериясе һәм номеры
______________________________________
тел.________________________________ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _
индексы булган почта адресы _
______________________________________

Аучылык билетын гамәлдән чыгару турында гариза

Минем аучылык билетын ________________________________ гамәлдән
(аучылык билетының хисап сериясе һәм номеры)
чыгаруыгызны сорыйм.

Башка мәгълүмат:

Әгәр кәгазьдә ау билетын гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә алырга кирәк булса, алу ысулларының берсен күрсәтергә:

а) вәкаләтле органда шәхсән үзе;

б) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә шәхсән (үзара хезмәттәшлек турында килешү нигезендә);

в) тапшыру турында хәбәр итеп, заказлы почта аша.

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

« » 20 ел _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ / _ _ _ _ _ _
(гариза бирүченең имзасы) / (имзаның расшифровкасы)

Татарстан
Республикасы Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитетының Аучылык билетын
бирү һәм гамәлдән чыгару буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына 3 нче кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин, ______________________________________________ _________________
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) тулысынча күрсәтелә)
яшәү адресы ___ ___ ___ ____ _____
__________________________________
_____________________________________
_______________
(индексын күрсәтеп, гариза бирүченең почта адресы, телефоны, электрон адрес)
_____________________________________________________________________
(гариза бирүченең шәхесен раслый торган документның исеме, аның сериясе,
_____________________________________________________________________
номеры, бирү датасы, документ биргән органның исеме)
_____________________________________________________________________

20___ елның «___» ________________ бирелгән сериясе _________ номеры _____ булган аучылык билетын рәсмиләштерү буенча дәүләт хезмәте нәтиҗәсен рәсмиләштергәндә җибәрелгән техник хатаны, сызуны төзәтүегезне сорыйм.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең яңадан рәсмиләштерелгән нәтиҗәсен алуга риза
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________

« » _ _ _ _ _ 20 ... ______________/_______________
ел (гариза бирүченең имзасы) / (имзаның расшифровкасы)

Татарстан
Республикасы Биологик ресурслар
буенча дәүләт комитетының Аучылык
билетын бирү һәм гамәлдән чыгару
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына 4 нче
кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Кемгә: ___________________________ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)

_________________________________

Элемтә өчен мәгълүматлар_ _ _ _ _ _

_________________________________

Документларны кабул итүдән баш тарту турында

хәбәрнамә

_ _ _

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан «Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару» дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата _______ елның ___ _________________ ____ номерлы гаризаны карау нәтиҗәләре буенча, Россия Табигать министрлыгының «Аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару тәртибен, аучылык билетын бирү формасын раслау турында» 2024 елның 24 ноябрендәге 579 номерлы боерыгына таянып, түбәндәге нигезләр буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документлар кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

---

Баш тарту сәбәбе:_ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _

Өстәмә мәгълүмат бирәбез:_ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _

---

Сез Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына, күрсәтелгән хаталарны бетергәннән соң, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза белән кабат мөрәҗәгать итә аласыз.

Әлеге баш тартуга карата, шикаятьне Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына җибәрү юлы белән судка кадәр тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

« » _ _ _ _ _ 20 ел _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ / _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _

(вәкаләтле затның имзасы) / (имзаның расшифровкасы)

Татарстан
Республикасы Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитетының Аучылык билетын
бирү һәм гамәлдән чыгару буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына 5 нче кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Кемгә: ________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)
____________________________________
Элемтә өчен мәгълүматлар - - - - - -
____________________________________

Аучылык билеты бирүдән баш тарту турында карар

...

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан «Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару» дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата _______ елның ___ _________________ ____ номерлы гаризаны карау нәтиҗәләре буенча, Россия Табигать министрлыгының «Аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару тәртибен, аучылык билетын бирү формасын раслау турында» 2024 елның 24 ноябрендәге 579 номерлы боерыгына таянып, түбәндәге нигезләр буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

Баш тарту сәбәбе:__ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _
__ _ _

___________________________________________________________________________

Өстәмә мәгълүмат бирәбез: _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _
___________________________________________________________________________
_

Әлеге баш тартуга карата, шикаятьне Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына җибәрү юлы белән судка кадәр тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

«_» -- - - - 20 ... ел _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ / __ _ _ _ _ _ _ _
(вәкаләтле затның имзасы) / (имзаның расшифровкасы)

Татарстан
Республикасы Биологик ресурслар
буенча дәүләт комитетының Аучылык
билетын бирү һәм гамәлдән чыгару
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына 6 нчы
кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

- - - - - - - № - - - - - - -
№ _ _ _ _ _ _ _ _ _

Дәүләт аучылык хуҗалыгы реестрына мәгълүматлар кертү турында ХӘБӘРНАМӘ

Хөрмәтле __________________________! - - - - -

Без Сезгә _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _
(мәгълүматны Реестрга кертү датасы)
дәүләт аучылык хуҗалыгы реестрына Сезгә тапшырылган бердәм федераль үрнәктәге аучылык билеты турында белешмәләр кертелүен хәбәр итәбез.

«Ау һәм аучылык ресурсларын саклау турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 4 өлеше нигезендә күрсәтелгән датадан Сезнең аучылык билеты гамәлдә дип таныла.

______________________________ ____________ __________________________
Бүлек башлыгы, район (районара) бүлеге башлыгы (имза) (фамилиясе, инициаллары)

Башкаручының Ф.И.А. (булганда),
телефоны

Татарстан
Республикасы Биологик ресурслар
буенча дәүләт комитетының Аучылык
билетын бирү һәм гамәлдән чыгару
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына 7 нче
кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

- - - - - - - № - - - - - -
На № _ _ _ _ от _ _ _ _ _

Аучылык билеты бирү турында ХӘБӘРНАМӘ

Хөрмәтле _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _

._ _ _ _
«Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару» дәүләт хезмәте күрсәтүгә _________ елның _______________ ___ номерлы гаризаны карау нәтиҗәләре буенча, «Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару тәртибен раслау турында» 2011 елның 20 гыйнварындагы 13 номерлы Россия Табигать министрлыгы боерыгына таянып, бердәм федераль үрнәктәге аучылык билеты бирү турында карар кабул ителде.

Өстәмә мәгълүмат: _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _

| ______________________ | ______________________ | ______________________ |
|---|---|---|
| Бүлек башлыгы, район (районара) бүлеге башлыгы | (имза) | (фамилиясе, инициаллары) |

Башкаручының Ф.И.А.
(булганда),телефоны

Татарстан
Республикасы Биологик ресурслар
буенча дәүләт комитетының Аучылык
билетын бирү һәм гамәлдән чыгару
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына 8 нче
кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

\- - - - - - - № - - - - - -
На № _____от

Аучылык билетын гамәлдән чыгару

турында ХӘБӘРНАМӘ

Хөрмәтле - - - - - - - - - - - - -

«Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару» дәүләт хезмәте күрсәтүгә _________ елның ________________ номерлы гаризаны карау нәтиҗәләре буенча, «Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару тәртибен раслау турында» 2011 елның 20 гыйнварындагы 13 номерлы Россия Табигать министрлыгы боерыгына таянып, аучылык билетын гамәлдән чыгару турында карар кабул ителде.

Өстә рәвештә хәбәр итәбез: гамәлдән чыгарылган аучылык билеты Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына аучылык билетын гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә алынганнан соң бер ай эчендә кире кайтарылырга тиеш.

Өстәмә мәгълүмат: _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _

| | | |
|---|---|---|
| Бүлек башлыгы, район (районара) бүлеге башлыгы | (имза) | (фамилиясе, инициаллары) |

Башкаручының Ф.И.А. (булганда),
телефоны

Татарстан
Республикасы Биологик ресурслар
буенча дәүләт комитетының Аучылык
билетын бирү һәм гамәлдән чыгару
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына 9 нчы
кушымта

Форма

| |
|---|
| **АУЧЫЛЫК БИЛЕТЫ**<br>сериясе номер |
| (аучылык билеты биргән Россия Федерациясе субъекты башкарма органы исеме<br>) |
| Фото өчен урын |
| (аучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) |
| (аучының шәхесен таныклый торган төп документ мәгълүматлары<br>) |
| Бирү датасы ______ 20_ ел вәкаләтле орган җитәкчесе яисә ул вәкаләт биргән вазыйфаи зат имзасы өчен урын (кәгазьдә аучылык билеты бирелгән очракта) |
| «Традицион яшәү рәвешен алып баруны тәэмин итү һәм традицион хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында аучылык шәхси куллануны канәгатьләндерү өчен кирәкле аучылык ресурсларын аулау күләмендә ирекле (бернинди рөхсәтсез) гамәлгә ашырыла» дигән тамга кую өчен урын |
| |

Татарстан Республикасы
Биологик ресурслар буенча дәүләт
комитетының аучылык билетын бирү һәм
гамәлдән чыгару буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ регламентына
кушымта (белешмә)

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Рәис | 211-66-94 | gkbioresursy@tatarstan.ru |
| Рәис Урынбасары | 211-66-94 | Radik.Mutaharov@tatar.ru |
| Идарә башлыгы | 204-84-13 | Pjotr.Kovkrak@tatar.ru |
| Бүлек башлыгы | 211-71-89 | Rim.Fathullin@tatar.ru |
| Өлкән белгеч | 211-71-89 | lKseniya.Samoylova@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Җир асты байлыкларыннан, табигый ресурслардан файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге башлыгы | 264-77-78 | Marat.Fashutdinov@tatar.ru |